**Гражданнарның Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү тәртипләре һәм шартлары**

Гражданин Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына туры килмәве турында Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Гражданин Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының һәм җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына шикаять белдерә ала.

Шикаять дөрес дип санала, әрәр дә:

1. закон яки башка норматив хокукый акт гражданнарның ирекләренә яки Конституциядә билгеләнгән хокукларына кагылса;
2. закон яки башка норматив хокукый акт судта яки башка органда каралган яки карала башлаган конкрет эшне хәл иткәндә кулланылган яки кулланылырга тиеш булса.

Судка мөрәҗәгать итәр өчен нәрсә эшләргә кирәк?

Билгеләнгән конкрет формадагы (форма бирелә) шикаятьне тутырырга, аңа кирәкле документларны өстәргә, тиешле күләмдәге дәүләт пошлинасын түләргә. Конкрет эшне хәл иткәндә шикаятькә Татарстан Республикасының шикаять белдерелә торган законын яки башка норматив хокукый актны куллану яки куллану мөмкинлеге булуны раслый торган документлар күчермәләре дә өстәлә.

Россия Федерациясе субъектларының Конституция судлары карый торган эшләр буенча физик зат мөрәҗәгать иткәндә дәүләт пошлинасы 300 сум күләмендә түләнә. Татарстан Республикасы Конституция суды, түләүченең матди хәленнән чыгып, аны әлеге суд карый торган эшләр буенча дәүләт пошлинасын түләүдән азат итәргә яки дәүләт пошлинасының күләмен киметергә, шулай ук аны түләүне, Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенең 333.41 статьясы нигезендә, кичектереп торылырга (бүлеп түләүне билгеләргә) мөмкин.

Югарыда күрсәтелгән статья нигезендә дәүләт пошлинасын кичектереп түләү яки бүлеп түләү кызыксынган зат ходатайствосы нигнезендә Россия Федерациясе Салым кодексының 64 статьясының 1 пунктында билгеләнгән сроклар чикләрендә мөмкин.

Кичектереп түләү яки бүлеп түләү билгеләнгән дәүләт пошлинасы суммасына кичектереп түләү яки бүлеп түләү билгеләнгән срокларга процентлар җыелмый.

Татарстан Республикасы Конституция суды 420060, Казан, Пушкин ур., 66/33 йорт адресы буенча урнашкан, телефоннары: (843) 264-74-76 – кабул итү бүлмәсе, (843) 264-74-83 – канцелярия. Рәсми сайт адресы - ksrt.ru; электрон почта адресы ksrt@ksrt.ru

Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарны кабул итә: дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе иртәнге 9.00 дән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга көнне – 9.00 дән 16.45 сәгатькә кадәр.

ҮРНӘК

Татарстан Республикасы Конституция судына

_____________________________________

(гариза язучының фамилиясе, исеме, этисенең исеме,

_____________________________________

адресы һәм башка мәгълүматлар )

**Гражданнарның Конституциядә билгеләнгән хокукларын һәм ирекләрен кысу турында**
**ШИКАЯТЬ**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясының дүртенче өлеше, “Татарстан Республикасында Конституция суды турында” Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының бишенче өлеше һәм 100 статьясы нигезендә, ________________________________________________________________________

(тикшерелергә тиешле норматив хокукый актның төгәл аталышы, номеры, кабул ителү датасы, бастырып чыгарылу чыганагы һәм башка мәгълүматлар)

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(тикшерелергә тиешле норматив хокукый актны эшләгән дәүләт хакимияте органының (жирле үзидарә органының) исеме, адресы)

чыгарылган актның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүен каравыгызны сорыйм.

Әлеге мөрәҗәгать өчен нигез булып мәсьәләдә ачыкланган, әлеге Законның (норматив хокукый актның яки аның аерым нигезләмәләренең) Татарстан Республикасы Конституциясенең _____ статьясына (статьяларына) туры килү-килмәве турындагы аңлашылмаучанлык тора.

Минем Татарстан Республикасы Конституциясенең __________ статьясы (статьялары) нигезендә каралган хокукларым һәм ирекләрем бозылу түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

________________________________________________________________________

(куелган мәсьәлә буенча гариза язучы позициясе һәм аның Татарстан Республикасы Конституциясенең тиешле нормаларына сылтама белән хокукый нигезләмәсе

________________________________________________________________________

Алда әйтелгәннәрдән чыгып, әлеге Закон (норматив хокукый акт яки аның (аларның) аерым нигезләмәләре) Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә дип саныйм һәм Татарстан Республикасы Конституция судыннан аны (аларны) Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип табуын сорыйм.

Әлеге эшне Татарстан Республикасы Конституция судында караганда минем мәнфәгатьләремне тәкъдим итүне ______________________

(гариза язучының вәкаләтле вәкиле турында мәгълүматлар)

_______________

____________________________________________________ ышанам һәм аңа “Татарстан Республикасы Конституция суды турында” Татарстан Республикасы Законының 54 статьясында каралган вәкаләтләрне тапшырам.

Гариза язучы: ___________________

(имза һәм дата)

Кушымта:

1) тикшерелергә тиешле акт тексты;

2) вәкил вәкаләтләрен раслаучы ышаныч кәгазе яки башка документ, шулай ук затның Татарстан Республикасы Конституция судында вәкил сыйфатында чыгыш ясау хокукын раслаучы документлар күчермәләре;

3) гариза язучының конкрет эшен хәл иткәндә Татарстан Республикасы норматив хокукый актының кулланылуын яки кулланылуы мөмкин булуын раслый торган документлар күчермәләре;

4) гариза язучының позициясен раслаучы документлар күчермәләре;

5) башка документлар һәм материаллар.

*Искәрмә: мөрәҗәгать, документлар, башка материаллар өч нөсхәдә күчермәләре белән биреләләр.*